**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 27 апрель № 252

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 26 апрель, 282 нче; 2013 ел, 29 апрель, 294 нче; 2013 ел, 29 июнь, 454 нче; 2013 ел, 19 июль, 507 нче; 2013 ел, 24 октябрь, 789 нчы; 2013 ел, 31 декабрь, 1110 нчы; 2014 ел, 15 март, 157 нче; 2014 ел, 14 апрель, 242 нче; 2014 ел, 11 июнь, 405 нче; 2014 ел, 9 июль, 475 нче; 2014 ел, 5 сентябрь, 644 нче; 2015 ел, 6 май, 326 нчы; 2015 ел, 16 май, 346 нчы; 2015 ел, 22 июль, 532 нче; 2016 ел, 17 февраль, 101 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында» 2012 ел, 31 декабрь, 1199 нче карары исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт программалары исемлеген һәм Татарстан Республикасының дәүләт программаларын, ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибен раслау турында»;

карарның 1 нче пунктындагы икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе (алга таба – Тәртип)»;

Татарстан Республикасының дәүләт программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибе»;

Тәртипнең 1.1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү, шулай ук аларны тормышка ашыру барышын тикшерүдә тоту кагыйдәләрен билгели.»;

Тәртипнең 1.2 нче пунктына түбәндәге эчтәлекле дүртенче абзац өстәргә:

«ведомство максатчан программасы – дәүләт программасының ярдәмче программасындагы билгеле бер бурычны хәл итүгә юнәлдерелгән, яраштырылган чаралар комплексын, шулай ук исәпләнә торган максатчан индикаторларны үз эченә алган документ. Ведомство максатчан программасы мөстәкыйль документ булып тора.»;

Тәртипнең 1.2 нче пунктындагы дүртенче – алтынчы абзацларны тиешенчә бишенче – җиденче абзацлар дип санарга;

Тәртипнең 1.5 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.5. Дәүләт һәм ведомство максатчан программаларын эшләүне һәм тормышка ашыруны яраштыру һәм методик җитәкчелек итү әлеге Тәртип нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

Тәртипнең 1 бүлегендәге 1.6 нчы пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.6. Дәүләт программасын эшләү һәм раслау әлеге Тәртипкә теркәлгән 1 нче кушымтада күрсәтелгән вакытларда гамәлгә ашырыла һәм үз эченә түбәндәге төп этапларны ала:

дәүләт программасы проектын эшләү;

дәүләт программасы проектын килештерү;

дәүләт программасы проектына экспертиза үткәрү, шул исәптән бәйсез экспертлар тарафыннан (кирәк булган очракта);

дәүләт программасын раслау.

Ведомство максатчан программасы бюджетны планлаштыру субъекты тарафыннан эшләнә һәм бюджетны планлаштыру субъекты җитәкчесе боерыгы белән раслана, ул шулай ук программаны тормышка ашыруны җаваплы вазыйфаи затны билгели.

Ведомство максатчан программасы, дәүләт программасы составына кергән очракта, дәүләт программасы кысаларында тормышка ашырыла.

Дәүләт программаларының аерым чаралары ведомство максатчан программалары формасында гамәлгә ашырыла ала.

Ведомство максатчан программасы чаралары башка ведомство максатчан программаларының, Татарстан Республикасы дәүләт программаларының (дәүләт программалары ярдәмче программаларының) чараларын кабатлый алмый.»;

Тәртипнең 4 бүлеге исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт программасын һәм ведомство максатчан программасын формалаштыру»;

Тәртипнең 4 бүлегенә түбәндәге эчтәлекле 4.4 нче пункт өстәргә:

«4.4. Ведомство максатчан программасы үз эченә түбәндәгеләрне ала:

а) программа паспорты;

б) ведомство максатчан программасын тормышка ашыру кирәклеген нигезләү һәм аның дәүләт программасы ярдәмче программасының максатына һәм бурычларына туры килүе, ведомство максатчан программасының дәүләт программасы ярдәмче программасының максатына ирешүгә һәм бурычын хәл итүгә керткән өлешен тасвирлау;

в) программаның төп максатлары һәм бурычлары;

г) программаны тормышка ашырудан көтелә торган нәтиҗәләрне тасвирлау һәм максатчан индикаторлар – еллар буенча программаны тормышка ашыру барышын һәм куелган бурычларны хәл итү буенча исәпләнә торган сан күрсәткечләре;

д) программа чаралары исемлеге һәм аларны тасвирлау, чаралар составын, кирәкле ресурслар (финанслау чараларын һәм чыганакларын файдалану юнәлешләрен күрсәтеп) һәм һәр чараны тормышка ашыру вакытлары турындагы мәгълүматны кертеп;

е) программаны тормышка ашыру вакыты;

ж) программаны тормышка ашыруның социаль, икътисадый һәм экологик нәтиҗәләрен тасвирлау, аның дәүләт программасы ярдәмче программасының максатына ирешүгә керткән өлешенең гомуми бәяләмәсен, аны тормышка ашыру куркынычлары бәяләмәсен;

з) программаны тормышка ашыру чоры дәвамында еллар яки этаплар буенча бюджет акчасыннан файдалану нәтиҗәлелеген бәяләү, кирәк булган очракта – аны тормышка ашырганнан соң;

и) ведомство максатчан программасын тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен нигезләү;

к) программаны тормышка ашыру өчен җавап бирә торган структур бүлекчәләр арасында вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлүне үз эченә алган программаны тормышка ашыру белән идарә итү системасын тасвирлау.»;

Тәртипнең 6 бүлеге исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Дәүләт программасын һәм ведомство максатчан программасын финанслау»;

Тәртипнең 6 бүлегендәге 6.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле 6.1.2 нче пункт өстәргә:

«6.1.2. Ведомство максатчан программаларын тормышка ашыруга бюджет ассигнованиеләре күләме әлеге Тәртипнең 6.1.1 нче пункты нигезендә тиешле дәүләт программасы кысаларында күздә тотыла.»;

Тәртипнең 7 бүлегендә:

бүлек исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7. Дәүләт программасын, ведомство максатчан программасын тормышка ашыру белән идарә итү һәм аларның үтәлешен тикшерүдә тоту»;

Тәртипнең 7.3 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3. Дәүләт программасына ведомство максатчан программаларының яңа ярдәмче программаларын, чараларын кертү һәм раслау дәүләт программаларын эшләү һәм тормышка ашыру өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.»;

7.4 нче пунктның өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ел саен, хисап елыннан соң килә торган елның 1 мартына кадәр, Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгына, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына – дәүләт программаларын тормышка ашыру эшләре барышы һәм финанс чараларыннан файдалану нәтиҗәлелеге турында мәгълүмат, шулай ук әлеге мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру хакында белешмәләр.»;

Тәртипнең 7.5 нче пунктында:

«г» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«г) чараларны үтәү өчен бюджет ассигнованиеләре һәм башка акчадан файдалану турында мәгълүмат (һәр дәүләт программасы буенча бюджетлар чыгымнарының максатчан статьялары нигезендә федераль бюджеттан, Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары финанслау күләмнәре хакында хисап мәгълүматлары яктыртылуны исәпкә алып);»;

түбәндәге эчтәлекле «е» пунктчасы өстәргә:

«е) ведомство максатчан программаларын тормышка ашыру турында аналитик мәгълүмат»;

7.5.1 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Дәүләт программасын тормышка ашыру нәтиҗәлелеген бәяләү дәүләт программасы күрсәткечләренең (индикаторларының) фактта ирешелгән мәгънәләрен һәм дәүләт программасында күздә тотылган планлаштырылган мәгънәләрне чагыштыру юлы белән дәүләт программасы максатына ирешү һәм бурычларын хәл итү дәрәҗәсен бәяләү нигезендә үткәрелә.

Күрсәткеч (индикатор), әгәр аның факттагы мәгънәсе планлаштырылган мәгънәдән 95 процenттан артык тәшкил итсә, ирешелгән булып санала.

Әгәр планлаштырылган мәгънәләр дәүләт программасы күрсәткечләреннән (индикаторларыннан) 95 процент һәм күбрәк ирешелгән булса, дәүләт программасы югары нәтиҗәлелек дәрәҗәсе белән тормышка ашырылган санала.

Әгәр планлаштырылган мәгънәләр дәүләт программасы күрсәткечләреннән (индикаторларыннан) 80 процент һәм күбрәк ирешелгән булса, дәүләт программасы канәгатьләндерерлек нәтиҗәлелек дәрәҗәсе белән тормышка ашырылган санала.

Әгәр планлаштырылган мәгънәләр дәүләт программасы күрсәткечләреннән (индикаторларыннан) 80 процент һәм азрак ирешелгән булса, дәүләт программасы

канәгатьләндерерлек булмаган нәтиҗәлелек дәрәҗәсе белән тормышка ашырылган санала.»;

Тәртипкә теркәлгән 5 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\252.doc

Татарстан Республикасының дәүләт программаларын һәм ведомство максатчан программаларын эшләү, тормышка ашыру һәм нәтиҗәлелеген бәяләү тәртибенә 5 нче кушымта
(Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 27 апрель, 252 нче карары редакциясендә)
Форма

| | |
|---|---|
| Дәүләт программасы реквизитлары, тормышка ашыру чоры | |
| Хисап бирә торган оешма исеме | |
| Дәүләт программасын раслау турындагы норматив хокукый акт исеме | |
| Форманы тутыру өчен җаваплы вазыйфаи зат (Ф.И.Ат.и., вазыйфасы, элемтә өчен телефоны) | |

20______ елның __________нә (на)
дәүләт программасын тормышка ашыру турында хисап

| Т/с | Ярдәмче програм-малар (бүлек, чара) исеме | Финанслау чыганагы (шул исәптән Россия Федерациясе бюджеты, Татарстан Республикасы бюджеты, җирле бюджет, бюджеттан тыш чыганаклар) | Хисап елына финанслауның планлаштырыл-ган күләмнәре*, мең сум | Бюджет йөк-ләмәләре лимитлары һәм бюджеттан тыш чыганак-лар нигезендә хисап елына финанслау күләмнәре **, мең сум | Ел башыннан үтәлгән***, мең сум | Үтәлү про-центы | Индика-тор исеме, үлчәү берәмлеге | Индикаторның мәгънәләре | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | үткән ел | | агымдагы ел | | | киләсе елга план |
| | | | | | | | | план | факт | план | факт | үтәлү про-центы | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7=6/5 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 | 13 | 14 |

| | | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | |
| Программа буенча барлыгы | | Барлыгы | | | | | | | | | | | |
| | | Россия Федерациясе бюджеты | | | | | | | | | | | |
| | | Татарстан Республикасы бюджеты | | | | | | | | | | | |
| | | җирле бюджет | | | | | | | | | | | |
| | | бюджеттан тыш чыганаклар | | | | | | | | | | | |

* бюджет акчасы өлешендә – тиешле финанс елына бюджет турындагы закон (карар) нигезендә, бюджеттан тыш акча өлешендә – программаны раслау турындагы норматив хокукый акт нигезендә;

** бюджет акчасы өлешендә – бюджет йөкләмәләре лимитлары хакында хәбәрнамәләр (лимитлары үзгәрү турында белешмәләр) белән җиткерелгән лимитлар нигезендә, бюджеттан тыш акча өлешендә – программаны раслау турындагы норматив хокукый акт нигезендә;

*** дәүләт программасы чараларын тормышка ашыруга касса чыгымнары чагылдырыла.